КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 апрель г.Казань № 373

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2026 елларда «Аутистик спектрында тайпылышлары һәм башка менталь бозулары булган инвалидларны социаль эш белән тәэмин итүгә ярдәм оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2025 ел, 5 июль, 486 нчы карары белән расланган 2025 – 2026 елларда аутистик спектрында тайпылышлары һәм башка менталь бозулары булган инвалидларны социаль эш белән тәэмин итүгә бәйле коммерциягә карамаган оешмаларның чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2026 елларда «Аутистик спектрында тайпылышлары һәм башка менталь бозулары булган инвалидларны социаль эш белән тәэмин итүгә ярдәм оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2025 ел, 5 июль, 486 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 18 ноябрь, 966 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2025 – 2026 елларда аутистик спектрында тайпылышлары һәм башка менталь бозулары булган инвалидларны социаль эш белән тәэмин итүгә бәйле коммерциягә карамаган оешмаларның чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.11 пунктның икенче абзацында татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктның беренче абзацында татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин